**Шәһәр күләмендә**
**җәмгыять белеме фэненнән үткәрелә торган**
**олимпиаданың мәктәп этабы сораулары**
**2017-18 уку елы**

**8-9 нче сыйныф.**

**Биремнәрне үтәү өчен 3 сәгать вакыт бирелә.**

**1. Лингвистик конструктор. Китерелгән сүзләрдән төшенчәнең билгеләмәсен төзегез һәм язып куегыз. Түбәндә сүз алып барыла торган төшенчәне атагыз.**

1.1. Хокукый, һәм, төркем, әхлакый, белән бәйләнгән, җаваплылык, нигезләнгән, кан кардәшлегенә, кече, никахка, яки

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________

1.2. Төзелгән, законнар, сайлаулар, югары, юлы белән, хакимият, чыгара торган, органы, вәкаләтле.

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________

**2. Сорауга җавап бирегез. Әгәр сезнең җавабыгыз түбәндәге гыйбарә белән туры килсә әйе, туры килмәгәндә юк дип билгеләгез.**
2.1. РФ Президенты РФ Конституциясенә каршы килүче законны юкка чыгарырга хокуклы.
2.2. Эшче кулына хезмәт килешүе экземплярын алмыйча, эшкә керешергә хокуксыз.
2.3. Барлык авторитар дәүләтләр унитар булып торалар.
2.4. Аралашу процессы вакытында субъект һәм объект арасында актив тәэсир итешү килеп чыга.
2.5. Татарстан Конституциясе 1992 елның 6 ноябрендә кабул ителде.
2.6. 1990 елның 30 августы ТССР (Татарстан) туган көне дип игълан ителә. 2.7. Конформизм ул кешеләр басымы астында үз фикеренне дәлилләү.
2.8. Мәдәни истәлекләр, театрлар һәм музейларга бай районны сәнгать районы дип атыйлар.
2.9. Салымнар җыйнау, социаль һәм мәдәни сфераларны акча белән тәэмин итү җәмгыятьнең икътисади сферасына карый.
**Җавап:**

| 2.1 | 2.2 | 2.3 | 2.4 | 2.5 | 2.6 | 2.7 | 2.8 | 2.9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |

**3. Сорауларга җавап бирегез. Дөрес җавап астына сызып куегыз.**

3.1 Кешеләрне Түбән Кама районында яшәүчеләр кебек бер социаль бергәлеккә берләштерүнең нигезендә нинди билге ята?

1) социаль-сыйнфый
2) этник
3) демографик
4) территориаль

3.2. Глобаль экологик проблемаларга нәрсә карый?
1) планетаның кайбер регионнарының ярлылыгы
2) атом-төш сугышы куркынычы
3) биологик төрләрнең күптөрлелеге кимүе
4) халык катламында өлкән яшьтәгеләр өлешенең артуы

3.3. Физик һәм юридик затлардан дәүләт бюджетына һәм җирле бюджетларга алына торган мәҗбүри түләүләр ул:
1) салымнар
2) льготалар
3) табышлар
4) пошлиналар

3.4. Законнарда һәм дәүләтнең башка актларында чагылыш тапкан, дәүләт тарафыннан саклanучы гомуммәҗбүри тәртип кагыйдәләре ничек атала?
1) әхлак нормалары
2) хокук нормалары
3) партия нормалары
4) традицион нормалар

3.5. Кешене шәхес буларак кайсы сыйфат характерлый?
1) иҗтимагый активлыгы
2) тышкы кыяфәт үзенчелекләре
3) темперамент сыйфатлары
4) физик һәм психик сәламәтлеге

3.6. Башка кечкенә төркемнәрдән аермалы буларак, гайлә нәрсә белән характерлана?
1) үзара көндәлек мөнәсәбәт белән
2) канкардәшлек мөнәсәбәтләр белән
3) уртак гореф – гадәтләр белән
4) бер-берсенә авыр минутларда терәк булуы белән

**4. Әлеге рәтләр нинди принцип буенча төзелгән? Алар өчен уртак булган төшенчәне билгеләгез**.
4.1. Ашау-эчү, куркынычсызлык, аралашу, хакимият казану, иҗат

_______________________________________________

4.2. Хезмәт хакы, рента, алимент, гонорар

_______________________________________________

**5. Түбәндә китерелгән рәтләрдән артык элементны табыгыз һәм астына сызыгыз. Үз җавабыгызны аңлатыгыз.**

5.1. Җенес (пол), яшь (возраст), профессия

______________________________________________________________

5.2. Бабай, бертуган абый, әти, улым, абый

______________________________________________________________

5.3. Мәгариф, дәүләт, гайлә, глобальләшү, чиркәү, юстиция

______________________________________________________________

5.4. Балалар, яшьләр, олылар, пенсионерлар, өлкәннәр

______________________________________________________________

**6. Түбәндә китерелгән исемлектән дәүләтнең функцияләрен билгеләгез һәм аларны күрсәткән саннарны җавапка языгыз.**

1) ил ихтыяҗларын халыкара аренада чагылдыру
2) дини оешмалар төзү
3) сайлауларда кандидатлар күрсәтү
4) илнең иминлеген саклау
5) бөлгенлеккә төшкән предприятиеләр акционерларына компенсацияләр түләү
6) законнар чыгаручы, башкаручы һәм суд хакимиятен тормышка ашыру

Сайлап алынган цифрларны үсә бару тәртибендә языгыз.

Җавап: _____________________________.

**7. Банк төре һәм банк функцияләре арасындагы тәңгәллекне ачыклагыз: беренче баганада бирелгән һәр позициягә икенче баганада туры килә торган позицияне сайлап алыгыз.**

| **Банк функцияләре** | **Банк төрләре** |
|---|---|
| А) акча эмиссиясе<br>Ә) предприяиеләрне кредитлау<br>Б) халыкның иректәге акча средстволарын мобилизацияләү<br>В) алтын валютасы резервларын саклау<br>Г) клиентларга исәпләү-касса хезмәте күрсәтү | 1) Россия Банкы<br>2) Коммерция банклары |

Сайлап алынган саннарны таблицага язып куегыз.

| А | Ә | Б | В | Г |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

**8. Анаграмманы чишегез. (хәрефләрне үз урынына куеп, җәмгыять белеменә караган сүзне языгыз).**

А) еешкееелллкк ________________________________

Б) оуккцрнеяин ________________________________

В) ппүкиатреелляк ________________________________

Г) ееттурвсин ________________________________

Д) ииртваомтзра ________________________________

Е) оемдркиаят ________________________________

**9. Түбәндәге ситуацияләрне хокук нормалары күзлегеннән чыгып анализлагыз.**

9.1. Ир кеше аерылышу нияте белән ЗАГС органнарына гариза белән мөрәҗәгать итә. ЗАГС хезмәткәрләре әлеге кешенең балигъ булмаган кызы булуын ачыклагач, гариза кабул итүне кире кагалар. Әлеге гражданин ЗАГС хезмәткәрләренең гамәлләре аның хокукларын бозуы турында белдерә.

**Бу очракта ЗАГС хезмәткәрләре хокуклымы? Үз җавабыгызны аңлатыгыз.**

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

____________________________

9.2. Баланы күршеләрнең эте тешли. Өйгә ул ертык курткасы һәм шактый каты кул җәрәхәте (травма) белән кайта. Баланың әти-әниләре күршегә дәгъва (претензия) ясарга килгәч, ул аларга гаепле булмавын, баланың артык каты куллары белән селтәвен һәм әлеге кискен хәрәкәтләргә этнең тәэсирләнүен белдерә.

**Бу очракта күрше хокуклымы? Баланың әти-әниләре җәрәхәтне дәвалау компенсациясен алу өчен нәрсә эшли алалар?**

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

____________________________

**10. Чит телләрдән кергән җәмгыять белеме терминнарын аларның турыдан-туры тәрҗемәләре белән туры китерегез.**

| **термин** | **тәрҗемә** |
|---|---|
| 1. Фәлсәфә | А) китап |
| 2. Этнос | Б) акыллылыкка мәхәббәт |
| 3. Коръән | В) халык |
| 4. Тотем | Г) буысынучанлык (покорность) |
| 5. Дин | Д) хикәяләү (повествование) |
| 6. Ислам | Е) борынгы баба (предок) |
| 7. Библия | Ж) бәйләнешле булу |

| | |
|---|---|
| 8. Миф | З) уку |

Җавап:

| 1. | 2. | 3. | 4. | 5. | 6. | 7. | 8. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

**11. Түбәндә китерелгән исемлектән экологик кризисның сәбәпләрен һәм нәтиҗәләрен билгеләгез. Җавабыгызны таблицага язып куегыз.**

а) кешенең тору мохите начарлануы
б) игенчелектә каты механик алымнар куллану
в) рациональ булмаган ресурслар куллану
г) күп кенә хайван һәм үсемлек төрләренең юкка чыгуы
д) табигатькә карата кулланучылар буларак мөнәсәбәт
е) промышленность калдыкларының артуы
ж) нәселдән килгән авыруларның артуы
з) “Бездән соң җир җимерелсә дә ярый” дигән тормыш принципы

| **Сәбәпләр** | **Нәтиҗәләр** |
|---|---|
| | |

**12. Түбәндә китерелгән текстны укып чыгыгыз, анда кайбер сүзләр төшереп калдырылган. Тәкъдим ителгән исемлектән сүзләрне буш калган урыннарга язып куярга кирәк.**

СССР таркалгач, яңа ________(1) дәүләтләр формалашкач, Татарстан да дәүләт суверенитеты турында ________(2) тормышка ашырды. Республика тарафыннан үткәрелгән сәясәт, аерым алганда, республика Дәүләт ______(3), РФ Дәүләт ______ (4), халык депутатларының җирле Советларына сайлаулар нәтиҗәләре уртаклык позициянең дөреслеген раслады.

ТР _______(5) нигезендә без _______(6), күп милләтле җәмгыять төзибез, анда кешенең кайсы милләткә каравы түгел, _________ (7) өстенлеккә ия. Шунлыктан һәр дәүләт хезмәткәре барлык халык мәнфәгатьләрен кайгырта.

А) суверен
Ә) Совет
Б) Дума
В) Декларация
Г) Конституция
Д) граждан
Е) күпмилләтле
Ж) Федераль
З) Региональ

**Түбәндәдәге таблицада бушлыкларның саннары күрсәтелгән. Һәр сан астына үзегез сайлап алган сүзләргә туры килгән хәрефләрне язып куегыз.**

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

**13. Культура төрләрен аларның билгеләмәләре белән тәңгәлләштерегез. Җавабыгызны таблицага язып куегыз.**

| **Культура төрләре** | **Билгеләмәләр** |
|---|---|
| А) матди культура | 1) бердәм тормыш кору формаларының җыелмасы |
| Б) рухи культура | 2) кеше ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тиешле предметлар |
| В) социаль культура | 3) Иҗади күренешләрне, танып белүне һәм дөньяны аңлауга юнәлдерелгән нормалар җыелмасы |
| | 4) торак, көнкүреш кирәк-яраклары, кием |
| | 5) нуклеар гайлә |

| А | Б | В |
|---|---|---|
| | | |

**14. Кеше тормышының ике периодын (яшьлек һәм өлкәнлек) аеруда икътисади, социаль һәм сәяси күрсәткечләр зур роль уйный. Кешенең мөстәкыйльлек табигате һәм аның күрсәткечләре арасында тәнгәллекне билгеләгез. Җавабыгызны таблицага язып куегыз.**

| **Кешенең мөстәкыйльлек табигате** | **Мөстәкыйльлек күрсәткечләре** |
|---|---|
| А) икътисади<br>Б) социаль<br>В) сәяси | 1) өйләнешү<br>2) сайлау мөмкинлеген алу<br>3) тормышны алып баруда мөстәкыйльлек<br>4) үзенне көнкүреш әйберләре белән тәэмин итү мөмкинлеге<br>5) эти-әниләрдән аерым яшәү<br>6) акчаны башкалардан бәйсез рәвештә куллану<br>7) закон адында җавап бирү мөмкинлеге |

| А | Б | В |
|---|---|---|
| | | |

**15. Схемада төшерелеп калган сүзләрне языгыз**

Дөнья диннәре

| | | |
|---|---|---|
| | | |

| | | |
|---|---|---|
| | | |

**17. Түбәндә билгеле һәйкәл - символлар сурәтләнгән. Аларның исемнәрен, кайда урнашканың һәм нәрсәне символаштырганың языгыз.**

1.  2. 

3.  4. 

1.______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

2.

______________________________________________________________________3.________________

______________________________________________________________________________________

_________________________________4._________________________________________________

______________________________________________________________________________________

**18. Түбәндә тәкъдим ителгән өземтәләрнең <u>берсен</u> сайлап алыгыз һәм күтәрелгән мәсьәлә буенча үз фикерегезне (карашыгызны, мөнәсәбәтегезне) бәян итегез. Үз карашыгызны нигезләү өчен <u>дәлилләр</u> китерегез.**

**Биремне үтәгәндә җәмгыять белеме курсыннан алган белемнәрегезне, туры килгән төшенчәләрне, шулай ук иҗтимагый тормыш фактларыннан һәм үз тормыш тәҗрибәгездән файдаланыгыз.**

**Темалар:**

1. «Халыкара сәясәт, барлык башка сәясәтләр кебек үк, хакимлек өчен көрәш ул» (Г. Моргентау).
2. «Хезмәт кешенең дәрәҗәсен күтәрә» (В.Г. Белинский).
3. «Ирекле милләт кенә милли характерга ия була ала» (Ж. де Сталь).
4. «Дефицит – ул бөтен нәрсәнең булуы, әмма кайда булуы билгеле булмау» (Д. Гвилава).
5. «Йомшак законнарга сирәк буйсыналар, катылары исә бик сирәк тормышка ашырылалар» (Б. Франклин).

6. «Икътисад ул чикләнгән ресурслар ярдәмендә чиге булмаган ихтыяҗларны канәгатьләндерү сәнгате» (Л. Питер).
7. «Сәясәттә үз илеңә яисә үз сайлаучыларыңа хыянәт итәргә туры килә. Мин икенчесен кулай күрәм» (Ш. Де Голль).